ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентябрь, 2017 ел № 19/4

Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 13/5 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерециясенең Бюджет кодексы, Россия Федерециясенең Салым кодексы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 13/5 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 30 гыйнварындагы 14/4, 2017 елның 22 февралендәге 15/5, 2017 елның 29 мартындагы 16/5, 2017 елның 20 июнендәге 17/4 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның 1 пунктчасында:

- икенче абзацта «8 052 271,98» саннарын «8 122 724,28» саннарына алыштырырга;

- өченче абзацта «8 791 547,49» саннарын «8 861 999,79» саннарына алыштырырга;

2) 14 пунктта:

- 1 пунктчада «2 772 454,23» саннарын «2 765 620,73» саннарына алыштырырга;

- 1 пунктчаның унбишенче абзацында «23 578,50» саннарын «16 745,0» саннарына алыштырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге 16.3 пунктын өстәргә:

«16.3. Шәһәр бюджетында Татарстан Респбуликасы бюджетыннан кергән субсидия күләмен исәпкә алырга:

1) китапханәләрнең китап фондын тулыландыру өчен 390,5 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Миинстрлар Кабинетының 2017 елның 31 июлендәге 1823-р санлы күрсәтмәсе нигезендә, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итүче муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү өчен 300,4 мең сум.»;

4) элеге Карарның 1-5 кушымталары нигезендә 1 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 2 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 4 нче, 6 нчы, 8 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев